**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**2025 елның «08» декабре** **31-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында», Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Среднедлевятовское сельское поселение» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 02 октябрендәге 1455/о номерлы Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының боерыгы белән КАРАР ИТТЕМ**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 5 февралендәге 91-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2022 елның 5 декабрендәге 91-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлегенең җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне раслау турында» 2024 елның 07 мартындагы 19-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Камская новь» район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб—адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**